Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№25 (118)
18 сентябрь 2014 ел

# «Аерылмагыз» кавыштырды



Влад Михневский фотосы

Юто Хисияма! Бу исемне һәр татар студенты белергә тиеш. Япониядә үзлегеннән 3 ел буе татар телен өйрәнеп, Халыкара олимпиадада җиңү яулап, татар телендә камил сөйләшүче әлеге 24 яшьлек студент – хәзерге көндә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге магистры.

## ● Вакыйгалар эзеннән

**КФУ** QS World University Rankings вузларның престижлы халыкара рейтингында **«551-600» ТӨРКЕМЕНӘ КЕРДЕ**. 2013нче елда уку йортыбыз «601-650» төркемендә иде. Шулай итеп, узган ел белән чагыштырганда, КФУ үз позицияләрен яхшыртты. Рейтингта дөньяның 863 уку йорты катнашкан. Топ-800гә Россиядән 3 яңа университет кергән һәм хәзер анда илебезнең 21 вузы тәкъдир ителгән.

• • • •

**15 СЕНТЯБРЬ** көнне КФУга РФдәге Куба Республикасының Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле вәкиле **ЭМИЛИО РАТМИР ЛОСАДА ГАРСИА** җитәкчелегендәге Куба Республикасы **ДЕЛЕГАЦИЯ**се **ВИЗИТ ЯСАДЫ**. Кунакларны КФУның Тышкы элемтәләр буенча проректор **Л.ЛАТЫЙПОВ** һәм Фундаменталь медицина һәм биология институты директоры **А.КИЯСОВ** каршы алды. Очрашу барышында Казан һәм Гавана университетлары, шулай ук Фундаменталь медицина һәм биология институты һәм Куба Республикасының Генлы инженерия һәм биотехнология үзәге арасында хезмәттәшлекне ныгыту мәсьәләләре турында сөйләштеләр.

• • • •

**15 СЕНТЯБРЬ** көнне **«СТУД'ЗВЕЗДА 2014»** яшьләр иҗади проектының **ФИНАЛЫ** булды. Сайлап алу туры нәтиҗәләре буенча финалга З.Вильданова (КФУ),Р.Мортазин(КАИ–А.Н.Туполев ис. КМТТУ), А.Әхмәтгәрәева (И.В.Әүхадиев ис. КМК) чыкты. Җиңүне исә университетыбызның Социаль-фәлсәфә фәннәре һәм гаммәви коммуникацияләр институтының 4 курс студенты Зарина Вильданова яулады. Тәбрик итәбез!

• • • •

**15 СЕНТЯБРЬ** көнне Якутскида студентлар арасында **БОКС** буенча **ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫ УЗДЫ**. Россия җыелма командасы составында КФУның Физик тәрбия һәм спорт институтының 2 курс студенты **А.ЗАЙЦЕВ** та бар иде. Антон 91 килограмма кадәр үлчәү категориясендә катнашып, бакыр медаль иясе булды. Аны бу зур җиңүе белән котлыйбыз!

• • • •

**15-19 СЕНТЯБРЬ** көннәрендә Прага шәһәрендә халыкара белем бирү өлкәсендә European Association for International Education (EAIE – 2014) **ЕВРОПА ФОРУМЫ УЗДЫРЫЛ**а. Анда КФУның кайбер департамент һәм бүлек җитәкчеләре дә катнаша. Чара барышында өйрәтмә семинар-тренинглар, студентларның халыкара рекрутингы буенча консультацияләр булачак. Аларны The Brenn-White Group Америка компаниясе оештыра. Шулай ук форумда КФУ үзенең халыкара программаларын тәкъдир итәчәк.

• • • •

**16 СЕНТЯБРЬ** көнне КФУның Н.И.Лобачевский ис. Фәнни китапханәсендә **«МЕДИЦИНА БУЕНЧА ЧИТ ИЛ НӘШРИЯТЛӘРЕНЕҢ ЭЛЕКТРОН РЕСУРСЛАРЫ»** исемле фәнни-белем семинары узды. Фәнни мәкаләләр авторларына Оксфорд университеты нәшрияте (Россиядә һәм БДБ илләрендәге вәкиллек), ProQuest, Ovid Technologies компанияләре, «КОНЭК» ЯАЖ ресурслары тәкъдир ителде. Чарада катнашучылар мәкаләләрне әзерләү буенча киңәш һәм тәкъдимнәр кабул итте, шулай ук нәшрият вәкилләренә үзләрен кызыксындырган сорауларны бирә алды.

• • • •

Сентябрь аенда КФУның Психологик үзәге **«ОЛЫ ТОРМЫШКА СТАРТ»** исемле яңа социаль проектын эшләтеп җибәрә. Проект булачак чыгарылыш студентларын яңа тормыш этабына психологик яктан әзерләүгә юнәлтелгән. Аның беренче этабында чыгарылыш курс студентларына яңа тормыш позициясен кабул итүдә туарга мөмкин булган кыенлыкларны аерып чыгару максатыннан психодиагностика үткәрәчәкләр. Икенче этап тренинг, консультация, мастер-класслар, психолог һәм эшлекле рольле уеннардан торачак.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

## ● Туган тел сагында

# «Телне саклау өчен бөтен шартлар да бар!»

**Шушы көннәрдә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында студентлар һәм актив яшьләр белән очрашты.**

**Ләйсән ИСХАКОВА**



Яшьләр Президентка республикадагы вәзгыять, шәһәр тормышы, халыкара белем алу, сәясәткә кагылышлы сорауларын бирде. Очрашу, нигездә, рус телендә барса да, татар теле, аның кулланылышы белән бәйле сораулар да яңгырады. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, сорауны төрле телдә бирергә була. «Кеше үз телен белә икән, бу аның үзе өчен, балалары өчен яхшы. Туган телне белү үзе бер шатлык бит ул!» – дип ассызыклады ул. Президент, телне саклау мәсьәләсенә тукталып: «Татар теле дәүләт теле булгач, балалар бакчасында да, мәктәптә дә өйрәтелә, Татарстанда телне саклау өчен бөтен шартлар да бар. Кадерен генә белмибез. Менә республикадан читтә хәлләр бөтенләй башка. Күптән түгел Самарада булдым. Андагы милләттәшләребез безгә үзебезнең милли мәктәп кирәк, диләр. Күп очракта аларда татар телен саклау өчен махсус татар теле курслары, якшәмбе мәктәпләре оештырыла. Менә аларга чыннан да авыр. Бу мәсьәләдә без аларга ярдәм күрсәтергә тиеш», – дигән фикер җиткерде.

Татарларның нибары 30 проценты гына Татарстанда яшәвен исәпкә алсак, бүген күпме кешенең ана телен өйрәнүгә мохтаҗ булуын күз алдына китерергә мөмкин. Бу уңайдан Татарстан үз ярдәмен күрсәтергә тырыша. Шул исәптән КФУ да. 2014-2020 елларда «Татарстанда барлык телләне үстерү» программасында татар телен саклау, аны пропагандалау, үстерүгә бәйле кызыклы проектлар тормышка ашырыла башлады инде. КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты әлеге программаны камилләштерүдә төп урынны алып тора.

Хәзерге вакытта КФУда Халыкара Казан лингвистик үзәге эшләп килә. Әлеге үзәк кысаларында инде берничә ел дәвамында халыкны татар теленә бушлай өйрәтү дә оештырыла. Шуны да билгеләп узу кирәк, әлеге курслар татарларда гына түгел, русларда да зур кызыксыну уятты.

Хәзер татар телен интернет аша «Ана теле» проекты ярдәмендә өйрәнергә була. Бу – читтә яшәүче милләттәшләребезгә туган телне саклау, өйрәнү өчен зур мөмкинлек. Татарча өйрәнергә теләк белдереп, әлеге сервиста теркәлүчеләр арасында Россия төбәкләрендә яшәүчеләр дә, Казахстан, Төркия, Украина, Үзбәкстан, Германия, Америка гомер кичерүче милләттәшләребез дә бар.

Арада башка милләт кешеләре дә бар. КФУда татар телен үзләштергән Америка, Германия, Италия һәм башка ил студентларыбелемнәрен әлеге онлайн-мәктәп ярдәме белән ныгыту мөмкинлегенә ия.

Санап үтелгән проектлар соңгылары түгел. Шуңа, Президентыбыз сүзен куәтләп, республикабызда татарлар өчен телне саклау һәм киләчәк буынга тапшыру өчен мөмкинләр зур дияргә кала. Барысы да үзебездән тора бит! Телне проектлар ярдәмендә түгел, ә үзара татарча сөйләшеп, фикер алышып та саклап калырга мөмкин!

## ● Иҗат үре

# Авылда - «Әдәби ишек алды»

**Узган атнада Универсиада авылында урнашкан Идел буе физик тәрбия, спорт һәм туризм академиясенең концертлар залында нәзакәтле француз сөйләме яңгырады. «Әдәби ишек алды» кысаларында үткән әдәби-музыкаль кичәнең кунагы француз язучысы һәм драматург Эрик-Эммануэль Шмитт иде.**

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

Шәһәр Мэриясе, Универсиада авылы, Казан федераль университеты, Идел буе физик тәрбия, спорт һәм туризм академиясе һәм «Альянс Франсез-Казань» француз теле һәм мәдәнияте үзәге белән берлектә оештырылган әлеге кичәдә катнашу бәхетенә Универсиада авылында яшәүче КФУ һәм академия студентлары да ирештe.

Чараны оештыручылар «Әдәби ишек алды»ның егерменче – юбилей әдәби-музыкаль кичәсен ничек итеп үзенчәлекле, кайда һәм кем өчен үткәрү турында озак уйлаган. «Бүгенге чараның шундый заманча студентлар шәһәрчегенең яңа бинасында узуы да очраклы түгел, чөнки бәйрәм иң яхшы югары уку йортларының берсе – КФУ студентлары өчен оештырылды», – ди алар.

Әдәби кичә танылган татар язучысы Г.Әпсәләмовның онытгы Альбина Әпсәләмованың чыгышы белән башланып китте. Ул тамашачыга үзе иҗат иткән шигырьләрен тәкъдим итте. Чара әдәби һәм музыкаль номерлар белән үрелеп барды. Болак буе театрында куелган Эрик-Эммануэль Шмиттның «Оскар и Розовая



> **✦ Белешмә**
>
> **Эрик-Эммануэль Шмитт 1960 елның 28 мартында туа. 1986 елда фәлсәфә докторы титулын ала һәм 3 ел дәвамында фәлсәфә фәнен укыта. Үзенең «Ночь в Валони» дип аталган беренче әсәрен 1991 елда яза. Иң танылган әсәрләре арсында «Золотой Джо», «Школа дьявола», «Распутник», «Дети Ноя» һ.б..**

мама» әсәрен сәхнәдә карау да залда утыручыларга зур бүләк булды.

Кичәнең төп кунагын зал көчле алкышлар белән каршы алды. Тамашачылар арасында студентлар гына түгел, ә Эрик-Эммануэль Шмиттның иҗатын сөюче казанлылар да бар иде. Сүз уңаеннан, очрашу алдыннан бер-ике көн эчендә Казан кибетләреннән авторның китапларын сатып алып бетергәннәр. Аның пьесалары утыздан артык телгә тәрҗемә ителеп сәхнәгә куелган. Танылган пьесаларының берсе – «Посетитель». Шул әсәре өчен язучы Мольер премиясенә лаек була.

Тамашачы белән аралашу барышында кунак Казан һәм Россия турындагы хис-кичерешләре белән уртаклашты. «Ерак аралар узып та, шундый матур залда, искиткеч кешеләр арасында мин үземне өйдә кебек хис итәм. Россиягә бу минем икенче визитым. Моңа кадәр мин Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләрендә генә булганым бар. Быел Франциянең Россиядәге илчелеге ярдәме белән мин Казанда да булу бәхетенә ирештем», – диде язучы.

Эрик-Эммануэль Шмитт рус мәдәнияте һәм әдәбияты белән дә таныш. Француз язучысы Ф.Достоевский, П.Чайковский иҗатларын якын күрә икән.

Кунак рус телен белмәгәнлектән, сорауларны һәм аларга җавапларны тәрҗемәче ярдәмендә алышты. Әдәби кичә автограф-сессия белән тәмамланды. Чарада чит ил атмосферасы өстенлек итсә дә, ул бик матур, җылы һәм үзенчәлекле үтте.

**Алар бездә укыган**

КФУ (ул заманда КДУ) студенты Зөлфирә Сәгъдиева - Швециядә Стокгольм университеты мөгаллимәсе!

# «Тормыш үзе өйрәтә ул!»

**Диләрә БАТРШИНА,**
Социаль-фәлсәфә фәннәре һәм гаммәви коммуникацияләр институты

*Кеше үз гомерендә кемгә дә булса охшарга тырыша. Үз кумирын ул, күбесенчә, зәңгәр экраннарда балкыган «йолдызлар» арасыннан эзли. Ә тирә-яктагы гади кешеләргә игътибар да итми. Ләкин, уйлап карасаң, нәкъ менә аралашып йөргән дустың яки танышыңның тормышын үз алдыңа үрнәк итеп куярга мөмкин бит. Кечкенә чагымда Зөлфирә апаны әниемнең чит илдән кайтып йөрүче классташы дип кенә кабул итә идем. Ә бүгенге көндә исә ул минем кумирыма әверелде. Мин аның ирешкән дәрәҗәсенә, активлыгына сокланып туя алмыйм. Зөлфирә апаның тормышы һәр кешегә үрнәк булырлык!*



Әтнә районы Күлле-Киме авылы кызы мәктәпне яхшы билгеләргә генә, үрнәк укучы булырак тәмамлый. Югары белемне Казан дәүләт университетында физика факультетының астрономия бүлегендә ала. Аннары Казанда 5 ел инженер-математик булып эшли. Үзлегеннән төрек телен өйрәнә, инглиз телен камилләштерә. Төрек, татар, рус, инглиз телләрендә яхшы сөйләшкәнлектән, Төркия төзелеш фирмасында алыштыргысыз тәрҗемәчегә әверелә. Шулай ук ул төрек яшьләренең «Азатлык» берлеге активисты була. Озакламый швед егете белән танышып, язмыш аның тормышын Швеция белән бәйли.

Беренче көннәрдә Швециядә инглиз телендә аралашкан Зөлфирә апа 3 ел эчендә швед телен дә өйрәнә. Җәмгыять белемен яңадан шведча укый, компьютер курсларына йөри. Тынгысыз Зөлфирә апа болар белән генә чикләнми. Стокгольм шәһәрендәге педагогика институтына укырга керә. Биредә, физика белеменнән тыш, ике ел ярым педагогик комплексы белем ала. Соңыннан 3 еллык гимназиядә шведча астрономия, математика һәм физика укыта. Шуны да әйтергә кирәк, Швециядә мондый гимназияләр – безнең илдәге техникум дәрәҗәсендәге уку йортлары. Мәктәп белеме алганнан соң, гимназиядә укымыйча, югары уку йортына керүп булмый икән.

2010 елдан Зөлфирә апа Стокгольм университеты каршындагы курсларда математика фәнен укыта башлый. Бүгенге көндә дә шунда эшли. «Курсларга гимназиядә белем алмаганнар килә һәм югары уку йортына керү өчен баллар туплый. Биредә укыту җиңел түгел, чөнки 1 еллык материалны 10 атна эчендә тулаем өйрәтеп бетерергә кирәк. 10 атна саен билге чыгарыла, имтиханнар алына. Сусамаган кешегә су эчертеп булмый. Ә миңа белемгә сусаган кешеләр килә. Аларны укыту бик рәхәт. Эшемне бик яратам, чөнки нәтиҗәсен күрәм», – ди ул.

Зөлфирә апаның шатлыгы, горурлыгы һәм иң кадерле кешесе – кызы Эмели. Халык телендә бала һәм әтиәни турында «Охшаса да охшар икән» дигән сүз яши. Эмели бар яктан да әнисенә охшаган, аның сәләтен тулысынча үзенә алган. Эмели да, әле 16 яшьтә генә булуына карамастан, 5 тел белә: шведча, инглизчә, русча, татарча, французча сөйләшә. Эмели музыка классларына йөри: скрипка, гитара, пианинода уйный, җырлый. Шулай ук балет классында шөгыльләнә. Киләчәктә үз тормышын музыка белән бәйләргә хыяллана. Швециядә яшәсәләр дә, Эмели үзен татар кызы дип саный. Татарстанга кайтырга ярата, мондагы кешеләрне күреп шатлана, биредә үзен яхшы хис итә. «Хәзер чит илдә дә яшәргә җиңел, чөнки компьютер, телефон бар, элемтә беркайчан да өзелми. Швециядә татарлар белән аралашабыз, җырлар тыңлыйбыз. Татар концертлары килсә, аларны калдырмыйбыз», – ди Зөлфирә апа.

Зөлфирә апа белән аралашу үзе бер рәхәт. Ул – яхшы, игътибарлы әңгәмәдәш, аның белән төрле темага сөйләшеп була. Шулай ук мин аның тагын бер сөйләшү үзенчәлеген игътибарга алдым: ул беркайчан да ике телне бутамый: я саф татарча, я саф русча сөйләшә! Бу аның тәрбияле, белемле булуын һәм, иң мөһиме, татар телен яратуын, хөрмәт итүен күрсәтә.

Шул ук вакытта Зөлфирә апа көчле рухлы кеше. Ул үз тормышында барлык авырлыкларны җиңә алган, теләкләренә, максатларына ирешкән. Ничек? Бу сорауга ул тыныч кына: «Тормыш барысына да үзе өйрәтә ул», – ди.

**Син һәм мин=БЕЗ!**

# «Безнең белән башла!»

**Эльвина НӘҖИПОВА,**
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

9-12 сентябрь көннәрендә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының 100дән артык иң сәләтле, өлгер, җитез 1 курс студентлары Марий-Эльнең Ял итү базасы Яльчикта булып кайттылар.



Бу сменаны җитәкләгән Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының социаль-тәрбия эшләрен алып бару буенча бүлек җитәкчесе Эльвира Рашат кызы Закирова үзенең хезмәткәрләре һәм 20гә якын өлкән студент-әйдаман белән, беренчеләрнең ялларын онытылмаслык итү өчен, зур өлеш керттеләр. Бу профильле сменада күп кенә психологик тренинглар; вокал, хореография, гаммәви мәгълүмат чаралары, СТЭМ, КВН, спорт, видеога төшерү, конферанс юнәлешләре буенча иҗади мастер-класслар үткәрелде.

Беренче көнне өлкән әйдаманнар тарафыннан бәйрәм концерты оештырылган булса, икенче көнне инде һәр легион, ягъни отряд, үз концертын – «Минута славы» чарасын тәкъдим итте.

Смена хәрәкәтле уеннар белән үрелеп барды. Психологик тренингларны Психология һәм белем бирү институты мөхтәрәм укытучылары: Наталья Викторовна Әхмәтҗанова, Җәмилә Ренатовна Ногманова һәм Миләүшә Ренатовна Хәйретдинова алып барды. Тренинглардан кала, «Веревочные курсы» станцияләре буйлап легионнар арасында ярыш, «Я – гражданин РФ» темасына дебатлар, егетләр арасында футбол, кызлар арасында волейбол ярышлары, «Что? Где? Когда?» һәм «Интуиция» кебек интеллектуаль уеннар оештырылды.

Рөстәм Барлас улы Камалов гаммәви мәгълүмат чаралары өлкәсендә иҗади мастер-класс, дебатлар үткәрде. «Индиго» заманлаштырылган хореография студиясе җитәкчесе Венера Рәҗәп кызы Галимова исә, кыска гына вакыт аралыгында 50дән артык студент белән бүген үк сәхнәгә куярлык бию әзерләде.

Әлбәттә, тыгыз эш арасында тәмле ашаулар, татлы йокылар да булмады түгел. Кыска гына вакыт эчендә беренче курс студентлары үзара дусляшты, бер зур гаиләгә әйләнде. «Бердәмлектә көч», «Хәрәкәттә бәрәкәт» дигән мәкальләрнең нәкъ тә менә безнең беренче курс студентларына туры килгәне расланды.

Эчтәлекле чаралар белән беррәттән, һәр елны институтлар арасында үтә торган «Беренче курслар көне» бәйрәменә әзерлек тә алып барылды. Һәр елдагыча, быел да «Начни с нами!» профильле смена мавыктыргыч, кызыклы вакыйгаларга, зур нәтиҗәләргә, файдалы, истә калырлык дәресләргә һәм, иң мөһиме, күп, якын дусларга бай булды!

*Студент булып йөргән чаклар...*

Сәгать иртәнге 7.45. Өченче тулай торактан аркасына рюкзак, кулына пакет тоткан икәү ут капкандай чыгып чапты. Ядрә тизлегендә Г.Кутуй тукталышына барып та җиттеләр. Парага соңга калучы студентлар түгел иде бу.

# Журналистларны көзен саныйлар

**Раил САДРЕТДИНОВ,** Социаль-фәлсәфә фәннәре һәм гаммәви коммуникацияләр институты

Дәрес «тозлаучылар» да түгел. Алар – КФУ татар журналистикасы бүлегенең өченче курс студентлары. Үзләренә укырга кергән беренче курс студентларын, багышлауга соңга калабыз, дип ашыгучылар иде.

Сәгать 8.00. Энәләр өстендә утыргандай, бөкеләргә көчкә түзеп барган бу студентлар кызыл автобус «Компрессорный»га якынлашканда гына җиңел сулыш алды. Билет кассасы янында җыелышкан «перваклар»ны күргәч, йөзләренә елмаю йөгерде. Һәр елны көзнең матур, кояш нурлары пәрәвез җепселләрен ялтыратып җәйне озаткан көнендә татар журналистикасы кафедрасында укучылар, укыганнар, кафедра укытучылары Каменка станциясе янәшәсендә урнашкан урман аланлыгына җыела. Кичә генә мәктәп бусагасын атлап чыккан укучыларны студентлыкка багышлау дип атыйбыз без бу бәйрәмне. Кафедрабызның барлык курста укучы студентларын бер гаилә дип күз алдына китерсәк, беренчеләр дә бу көннән шул гаиләгә әгъзалары булып китәләр.

Алтын төсләргә төренеп каршы алган аланлык шау килде. Һәр курс үзе белән таныштыра, кызыклы чаралар уйлап килә бирегә. Кемнең фантазиясе ничек эшли инде! Уены-чыны бергә, кадерле укытучыларыбызга пародияләр күрсәтсәк тә, үпкәләү дигән әйбер юк. Чөнки без – барыбыз бер гаилә! Ә иң мөһиме, беренче курс студентлары анты: «Газеталарга балык төрмәскә! Редакция көнен редакциядә уздырырга! Шимбә көнне соңгы парага шат күңел белән килергә!.. Ант итәм, ант итәм, ант итәм!..»

Быел кафедрага «өр-яңа» 11 кыз аяк басты. Алар – Татарстаныбызның төрле районнарыннан. Беренче сессия ябылмыйча торып, студент булып булмый, диләр. Мин аларның КФУ студентлары, татар журналистлары дигән исемгә тап төшермичә, укытучыларыбызның йөзенә кызыллык китермичә, исән-имин башлаган юлны уңышлы тәмамлауларын теләр идем. Ак юл сезгә, перваклар!



● Таныш бул!

# «Аерылмагыз» кавыштырды

Алинә САДЫЙКОВА

**Юто шушы көннәрдә Япониянең башкаласы – Токиодан татар телен фәнни яктан өйрәнү өчен Казанга килде. Инглиз, төрек, япон, башкорт телләрен яхшы белгән япон егете белән рәхәтләнеп саф татар телендә сөйләшеп утыру үзе могҗизага тиң! Аның шул дәрәҗәдә камил сөйләшүенә, төпле фикер йөртүенә сокланмыйча булмый!**

**– Юто, татар теле белән ничек кызыксына башладың?**

- Япониядә университетта 4 ел буе төрек телен укыдым. Ул вакытта минем өчен серле төрки дөнья ачыла башлады. Әнче курста укыганда, интернетта очраклы рәвештә «Аерылмагыз» җырына юлыктым. Ул миңа бик ошады һәм минем татар теле турында беләсем килде. Шул рәвешле, татар теле минем тормышыма килеп керде һәм үзенә гашыйк итте. Менә инде 3 ел буе мин аны өйрәнәм, серләренә төшенәм.

**- Татар теле җиңел телләрдән түгел. Япониядә татар китаплары да күп түгелдер. Син аны ничек өйрәндең?**

- Интернетта бөтен әйбер дә бар бит. Башта Татарстан, Казан турында мәгълүмат җыйдым. Нинди як булуы, үзенчәлекләре белән таныштым. Аннары радиотапшырулар тыңлап, ТНВ-Планета каналын карап, төрле матбугат чараларыннан файдаландым. Күпчелек очракта «Азатлык» радиосының сайтында татарча язылган материалларны укый-укый өйрәнүемне дәвам иттем. Шулай ук безнең китапханәдә немец телендә язылган татар теленә өйрәтү китабы бар иде. Шуларны укыдым. Немец телен яхшы белмәсәм дә, татар теле төрек теленә бик охшаган. Шуңа күрә үзлегемнән татар телендә язылган әлешен укып өйрәндем.

**- Япониядә дә татарлар бар бит. Син алар белән аралашкансыңдыр инде?**

- Әйе, Токиода алар нигез салган мәчет тә бар. Анда йөзләп кеше йөри. Алар үзара татарча сөйләшәләр. Минем алар белән якыннан аралашу мөмкинлегем булмады. Мин күбрәк социаль челтәрләрдә аралаштым. Казанга килгәч, миңа алар белән күрешеп аралашу да насыйп булды. Аннары моннан ике ел элек Токиога модель булып эшләүче бер татар егете килгән иде. Ул - минем беренче татар дустым.

**- Юто, син быел Казанда уздырылган татар теле һәм әдәбиятыннан II Халыкара олимпиадасы җиңүчесе. Анда ничек катнашырга уйладың? Гомумән, әлеге чара турында каян белдең?**

- Әлеге олимпиада турында мин Америкада яшәүче дустымнан белдем. Ул Япониядә туып-үскән татар кешесе. Тиешле мәгълүматны бирде һәм мин катнашырга, үз көчләремне сынап карарга булдым. Интернет аша бирелгән тестны башкарып чыктым. Аннары мине бирегә чакырдылар.

**- Олимпиада биремнәре авыр булдымы соң?**

- Юк, минем өчен алай ук авыр булмады. Миңа хыялым һәм аны тормышка ашыру юллары турында сөйләргә кирәк иде.



**- Ә синең хыялың нинди?**

- Казанда берничә ел торып, татар телен яхшылап, тирәнтен өйрәнү. Аннары туган ягыма, Японияга кайтып, андагы җирле халыкны да татар теле белән таныштырып, бу гаҗәеп матур телнең серләренә төшендерәсем килә.

**- Япония университетында тагын татар телен өйрәнүчеләр бармы соң?**

- Өйрәнергә теләүчеләр бар, ләкин бездә, гомумән, татар телен өйрәнү мөмкинлеге юк. Укытучылар юк, китаплар да аз. Шуңа күрә Казанга килдем дә.

**- Ә Казанга беренче тапкыр килүең кайчан булды?**

- Монда беренче тапкыр нәкъ бер ел элек, 2013 елның сентябрь аенда килгән идем. Шәһәр, аның кешеләре белән махсус танышыр өчен. Бу минем чит илгә беренче сәяхәтем иде. Казан миңа беренче күрүдән үк бик ошады, ләкин бераз салкын булды. Бездә, гадәттә, 30 градус җылы. Кыш булмый диярлек. Кар елга ике-өч тапкыр яварга мөмкин. Иң салкын дигәнебез – 5 градус.

**- Гаиләдә синең татар телен өйрәнә башлавыңны һәм Казанда укырга теләвеңне ничек кабул иттеләр?**

- Әти-әни һәм сеңелләрем чит телләр белән кызыксынганымны, мавыкканымны беләләр. Шуңа күрә минем бу адымым алар өчен шаккатырлык вакыйга булмады.

**- КФУ магистры буларак, синең хис-кичерешләрең?**

- Мин монда 4 сентябрь көнне килеп җиттем. Универсиада авылында ике егет - Кытай татарлары белән бергә яшим. Алар да мин укыган институтта укыйлар. Әкренләп ияләшеп киләм. Укытучылар - бик яхшы кешеләр. Алар миңа гел ярдәм итеп торалар. Урыс телен яхшы белмәү генә авырлыклар тудыра.

**- Юто, менә синең хыялың Япониягә кайтып, анда татар телен укыту. Бу ниятеңне тормышка ашыру өчен, сине гаиләдә дә аңларга, синең карашларыңны уртаклашырга тиешләр. Андый очракта татар кызына өйләнер идеңме?**

- Әлбәттә! Татар кызлары бик мөлаем һәм сөйкемле. (Бу уңайдан, Ютоның бәхете бар икән. Татар филологиясе бүлегендә кызлар бик күп. Татар кызлары, бәхетегезне кулдан ычкындырмагыз! – *А.С.*)

*Әлеге әңгәмә беренчесе булса да, соңгысы түгел! Бу гаҗәеп шәхес белән танышуны алга таба да дәвам итәрбез. Ә Ютога зур эшендә уңышлар һәм тел ачкычлары телибез. Афәрин, Юто!*

● Еракта якын кардәшләр




# Татар кызлары «көрәште»

**11 сентябрь көнне Чиләбедә «Трактор» боз сараенда «Татар кызы – 2014» бәйгесенең күптән көтелгән финалы узды.**

**Гүзәлия ГЫЙНИЯТУЛЛИНА,** Социаль-фәлсәфә фәннәре һәм гаммәви коммуникацияләр институты

«Татар кызы» төбәкара конкурсы елдан-ел таныла, популярлаша бара. Урал төбәгендә соңгы дүрт елда киң күләмдә үткәрелә торган әлеге бәйгеләр – татар халкының мәдәни үзәкләренең берсе булып торган Чиләбе татарларының да, бөтен Көньяк Уралда яшәүче халкыбызның да тормышында күренекле вакыйга.

«Татар кызы – 2014» бәйгесендә 30 гүзәл зат 5 ай дәвамында чибәрлектә, уңганлыкта, тапкырлыкта, житезлектә көч сынашты. Кызлар туган якларын өйрәнделәр, Чиләбе өлкәсенең Кунашак районы Сабантуенда, өлкә табигатенең матур урыннарында булдылар, кул тегерменендә он тарттырып та карадылар, кияү пилмәне пешерделәр, хәтта зәркән әйберләр – беләзекләр ясадылар, спорт ярышларында үзләрен күрсәттеләр – гер күтәрделәр, көрәштеләр.

Күпләргә бу төр бәйгеләр үткәрү бик үк аңлашылып бетмәскә дә мөмкин. Тик



кызларны бу рәвешле сынауның үз нечкәлеге бар – татар хатыннары гомер-гомергә бар яктан да килгән, уңган булулары белән аерылып торган, кирәк икән, ир-ат эшен дә җиренә җиткереп башкарганнар. Шуңа күрә, әлеге матурлык бәйгесенең төп максаты да иң чибәр татар кызын сайлап алу гына түгел, ә аларның уникаль эчке дөньясын ачып бирү, кызларның ни дәрәҗәдә милли гореф-гадәтләргә, традицияләргә тугры булуларын ачыклау.

Барлык сынауларны уңышлы гына үткәннән соң, 12 кыз финалга чыкты. 11 сентябрь көнне уникке чибәркәй арасыннан бер җиңүче сайлап алынды. Ул Башкортстанның Юкәлекүл авылында туып үскән, хәзер Чиләбе өлкәсенең Миасс шәһәрендә яшәүче 26 яшьлек Зәлия Әхтәмова булды. Зәлия Башкорт дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлаган, бүгенге көндә реклама буенча менеджер булып эшли. Җиңүче кыз турында бирелгән мәгълүматларда «ата-анасы йортында татар теле исән» диелгән. Зәлия ахырга кадәр иң чибәр, иң оста, уңган булган татар кызы исемен яулаячагына ышанмаган. Әлеге бәйгегә кыз чын күңеленнән рәхмәтле.

Финал концертында Татарстанның атказанган артистлары Артур Минһаҗев һәм Марат Галимов, Эльмира Кәлимуллина татар җырлары белән күңелне җылыттылар. Шулай ук Алман иленнән килгән виртуоз баянчы Айдар Гайнуллин татар халык көйләрәнә тезмә башкарды, Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле чыгышы чараны тагын да бизәп җибәрде һәм барыбыз да яраткан «Буран әбиләре» татарча да җырладылар. Ә бәйге инде күмәкләп «Туган тел» җырын башкару белән тәмамланды.

«Татар кызы» конкурсы, халкыбызның тарихи кыйммәтләрен югалтмыйча, чын татар кызларын берләштерә. Мондый конкурслар, минемчә, тарихыбызны, мәдәниятебезне, туган телебезне сакларга һәм үстерергә, онытмаска ярдәм итә.



DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.